| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА**<br>**Терсинского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Тирсә авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР** |

27.11.2019 Тирсә авылы № 7

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Тирсә авыл җирлеге башлыгы к а р а р б и р д е:

1. 2019 елның 08 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Тирсә авылы мәдәният йорты бинасында Халык җыенының беренче этабы уткәреләчәк. Тирсә авылында Вокзал, Дуслык, Болын, Дөнья, Күл, Кыр, Бакча, Совет, Хезмәт урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча билгеләргә.

2. 2019 елның 10 декабрендә 13 сәгать 00 минутта Тирсә авылы мәдәният йорты бинасында гражданнар Җыенының икенче этабын Үзәк, Көнчыгыш, Заречная, Яр буе, Яшьләр, Беренче Май, Нагорный, Мәктәп урамнары үзара салым кертү мәсьәләсе буенча билгеләргә.

3. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Тирсә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:
«Тирсә авыл җирлегенең Тирсә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә житкән), торып укучы студентлардан, ироктән мәхрүм ителгән физик затлардан тыш, 2020 елда узара салым акчасын 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә юнәлтергә Сез ризамы:

1. Кышкы чорда урамнарны кардан чистарту
2. Хезмәт һәм Вокзал урамнарынның суүткәргечен үзара тоташтыру;
3. Тирсә авылында урам юлларын ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК".

5. Тирсә авыл жирлеге Башкарма Комитетына халык җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

6. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://agryz.tatarstan.ru Тирсә авыл жирлегенең мәгълүмат стендларында да халык җыены этаплары үткәрелергә 10 көннән дә соңга калмыйча.

7. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Терсинского сельского поселения Тирсә авыл жирлеге Советы ИНН 1601002597

Р.Р. ЗАКИРОВ